| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.11.2021 с.Старое Дрожжаное № 461

Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан физик һәм юридик затларга күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү турында» 2014 елның 28 апрелендәге 270 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан физик һәм юридик затларга күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү турында» 2014 елның 28 апрелендәге 270 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы балаларына физик һәм юридик затларга бирелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү турында нигезләмә» 1 нче кушымтада түбәндәге эчтәлекле 4.2 - 4.4 пунктларын өстәргә:

4.2. Түләүле хезмәтләр исемлеге муниципаль бюджет учреждениесенең куллану ихтыяҗын һәм мөмкинлекләрен исәпкә алып төзелә һәм халыкның ихтыяҗлары контекстында даими рәвештә төзәтелә.

4.3. Анның үзкыйммәте (үзкыйммәтенә карамаган салымнар һәм җыемнардан башка) хезмәт күрсәтүгә бәянең артуы процентлы мөнәсәбәттә 40% тан да артык булмаска мөмкин.

4.4. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» МКУ җитәкчесе хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең дөреслеген һәм акчаларны вакытында тапшыруны тикшереп тора.;

2) 2 нче кушымтада «Физик һәм юридик затларга «Авылара мәдәният йорты», «Авылара китапханәсе», «Туган якны өйрәнү музее» һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Балалар сәнгать мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан бирелә торган түләүле хезмәтләр исемлеге һәм күләме», «2014 елга «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган (башкарыла) түләүле хезмәтләр бәяләре турында мәгълүмат» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

*«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе* тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләрнең бәяләре турында мәгълүмат»

| № т/б | Хезмәтнең атамасы | Үлчәү берәмлеге | Бәясе |
|---|---|---|---|
| 1. | Даими һәм вакытлыча экспозицияләр, күргәзмәләр белән танышу (карау):<br><br>- 7 яшьтән 18 яшькә кадәр;<br><br>- олыларга | сум. | 50<br><br>100 |
| 2. | Музей хезмәтләре:<br><br>-күзәтү һәм тематик экскурсияләр үткәрү;<br><br>- лекция хезмәте күрсәтү | сум. | 100 |
| 3. | Мәдәни-тамаша чаралары үткәрү | сум. | 150 |
| 4. | Музейга түләүсез керү хокукына ия гражданнар категорияләре:<br><br>- I һәм II төркем инвалидлар;<br><br>-Бөек Ватан сугышы ветераннары;<br><br>- чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләр;<br><br>- һәр айның беренче сишәмбесе, барлык | сум. | түләүсез |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | категория гражданнар өчен;<br><br>- 7 яшькә кадәр балалар;<br><br>-ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар;<br><br>-балалар төркемен озатып йөрүче педагоглар һәм тәрбиячеләр;<br><br>- дәүләт һәм муниципаль музей хезмәткәрләре | | түләүсез |
| 5. | - Экспозицияне фотога төшерү<br>- Кесә телефонына төшерү | сум. | 70<br>30 |
| 6. | Ксерокопия ясау (1 бит):<br><br>-Музей фондыннан бастырылган материалларны;<br>-Бастырылмаган материалларны;<br>-Заказчы материалларын | сум. | 30<br><br>100<br>10 |
| 7. | Методик ярдәм күрсәтү | сум. | 100 |
| 8. | Сувенир продукциясен сату | сум. | Килешү бәясе буенча |

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Д.А. Сатдинов